ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында” Татарстан Республикасы Законының 5[1] һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында” 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, №7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5[1] статьяның 5 пунктында “Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсенең” сүзләрен “Россия Федерациясе Югары Суды каршында Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсенең (алга таба – Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Җәмәгать судьяларының айлык акчалата бүләкләү, квартал саен акчалата кызыксындыру, хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган башка түләүләрне һәм федераль законнар белән судьялар өчен каралган социаль түләүләрне тәэмин итү, шулай ук торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ җәмәгать судьяларын торак урыннар белән тәэмин итү Россия Федерациясенең чыгымнар йөкләмәсен тәшкил итә һәм Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе аша башкарыла.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты шушы Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2014 елның 20 ноябре
№ 89-ТРЗ